КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 29 август г.Казань № 648

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2025 ел, 15 апрель, 321 нче карары белән расланган Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2025 ел, 15 апрель, 321 нче карары белән расланган Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге Тәртиптә кулланылган төшенчәләр, Федераль һава транспорты агентлыгының Россия Федерациясе территориясендә пассажирларны төбәк һава

ташулары һәм төбәк маршрут челтәрен формалаштыру өчен һава транспорты оешмаларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү тәртибе турында 2024 елның 26 ноябрендәге 22-64160-00191-Р номерлы карарында кулланылган мәгънәдә кулланыла (алга таба – Карар).»;

13 пунктта:

унберенче абзацта «федераль кагыйдәләрнең 5 нче» сүзләрен «Карарның 6 нчы» сүзләренә алмаштырырга;

егерменче абзацта «федераль кагыйдәләрнең 5 нче» сүзләрен «Карарның 6 нчы» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктның өченче һәм дүртенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Карарның 5 нче кушымтасында китерелгән территориянең ераклыгын һәм аңа кадәр барып җитү авыр булуны исәпкә ала торган коэффициентларга арттырылган, Карарның 6 нчы кушымтасында китерелгән әлеге күрсәткечнең иң чик күрсәткечләре – Караның 6 нчы кушымтасында кертелгән Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендәге пунктлардан (пунктларга) маршрутлар өчен;

Карарның 5 нче кушымтасында китерелгән әлеге күрсәткечнең иң чик күрсәткечләре – башка маршрутлар өчен.»;

7 пунктның икенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге Тәртипнең кушымтасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-Министры А.В.Песошин

Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибенә кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 29 август, 648 нче
карары редакциясендә)

2024 елга Татарстан Республикасы территориясеннән һәм (яки) территориясенә гамәлгә ашырыла торган һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүнең субсидия бирелә торган маршрутлары исемлеге

| Т/с | Һава транспорты белән пассажирлар йөртү маршрутлары | | Атнага рейс-лар ешлы-гы | Елга рейс-лар ешлы-гы | Махсус тариф-ның чик зурлы-гы, сум | Бер парлы рейска Татарстан Республикасы бюджетыннан авиапасса-жирлар йөртүчеләргә бирелә торган субсидия күләме, сум | Һавада йөртүләрне башкару чоры |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | очып китү аэропорты | барып җитү аэропорты | | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1. | Бөгелмә | Нижневар-товск | 2 | 78 | 8 538,0 | 366 125,0 | 02.01.2025 – 31.05.2025; 01.09.2025 – 31.12.2025 |
| 2. | Бөгелмә | Яңа Уренгой | 2 | 78 | 9 987,0 | 366 125,0 | 02.01.2025 – 31.05.2025; 01.09.2025 – 31.12.2025 |
| 3. | Бөгелмә | Сургут | 2 | 78 | 8 055,0 | 366 125,0 | 02.01.2025 – 31.05.2025; 01.09.2025 – 31.12.2025 |
| 4. | Бөгелмә | Усинск | 2 | 78 | 7 089,0 | 274 748,0 | 02.01.2025 – 31.05.2025; 01.09.2025 – 31.12.2025 |
| 5. | Бөгелмә | Ноябрьск | 2 | 78 | 8 538,0 | 366 125,0 | 02.01.2025 – 30.06.2025; 01.09.2025 – 31.12.2025 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6. | Казан | Әстерхан | 2 | 41 | 6 123,0 | 250 266,1 | 01.05.2025 – 30.09.2025 |
| 7. | Казан | Барнаул | 2 | 54 | 10 953,0 | 282 709,7 | 01.01.2025 – 30.04.2025; 01.10.2025 – 31.12.2025 |
| 8. | Казан | Волгоград | 2 | 56 | 5 157,0 | 180 791,2 | 01.01.2025 – 30.04.2025; 01.10.2025 – 31.12.2025 |
| 9. | Казан | Горно-Алтайск | 2 | 69 | 10 953,0 | 366 125,0 | 01.05.2025 – 31.12.2025 |
| 10. | Казан | Иркутск | 2 | 41 | 10 953,0 | 492 722,62 | 01.01.2025 – 30.04.2025; 01.10.2025 – 30.11.2025 |
| 11. | Казан | Калуга | 2 | 97,5 | 5 157,0 | 190 584,9 | 02.01.2025 – 31.12.2025 |
| 12. | Казан | Кемерово | 2 | 43 | 10 953,0 | 282 709,7 | 01.01.2025 – 30.04.2025; 01.10.2025 – 30.11.2025 |
| 13. | Казан | Киров | 2 | 99 | 2 741,0 | 100 121,67 | 02.01.2025 – 31.12.2025 |
| 14. | Казан | Магнито-горск | 2 | 56 | 4 191,0 | 95 134,99 | 02.01.2025 – 30.04.2025; 01.10.2025 – 31.12.2025 |
| | | | 2 | 17 | 4 191,0 | 148 161,05 | 01.05.2025 – 31.05.2025; 01.09.2025 – 30.09.2025 |
| 15. | Казан | Мурманск | 2 | 55 | 9 021,0 | 246 361,31 | 01.01.2025 – 30.04.2025; 01.10.2025 – 31.12.2025 |
| 16. | Казан | Нальчик | 2 | 43 | 8 055,0 | 347 818,75 | 01.05.2025 – 30.09.2025 |
| | | | 2 | 26 | 8 055,0 | 223 336,25 | 01.10.2025 – 31.12.2025 |
| 17. | Казан | Нижневар-товск | 2 | 78 | 9 021,0 | 366 125,0 | 02.01.2025 – 30.06.2025; 01.09.2025 – 31.12.2025 |
| 18. | Казан | Түбән Новгород | 2 | 69 | 2 741,0 | 96 076,35 | 01.05.2025 – 31.12.2025 |
| 19. | Казан | Новокузнецк | 2 | 43 | 10 953,0 | 282 709,7 | 01.01.2025 – 30.04.2025; 01.10.2025 – 30.11.2025 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 20. | Казан | Яңа Уренгой | 2 | 78 | 9 987,0 | 366 125,0 | 02.01.2025 – 31.05.2025; 01.09.2025 – 31.12.2025 |
| 21. | Казан | Омск | 2 | 56 | 8 538,0 | 246 361,31 | 01.01.2025 – 30.04.2025; 01.10.2025 – 31.12.2025 |
| 22. | Казан | Оренбург | 2 | 2 | 3 708,0 | 103 587,76 | 01.03.2025 – 09.03.2025 |
| | | | 2 | 69 | 3 708,0 | 130 799,8 | 01.05.2025 – 31.12.2025 |
| 23. | Казан | Пермь | 2 | 61 | 3 225,0 | 72 839,49 | 02.01.2025 – 30.04.2025; 01.10.2025 – 31.12.2025 |
| 24. | Казан | Петрозаводск | 2 | 43 | 6 606,0 | 123 667,5 | 01.05.2025 – 30.09.2025 |
| 25. | Казан | Салехард | 1 | 52 | 8 538,0 | 205 974,21 | 02.01.2025 – 31.12.2025 |
| 26. | Казан | Самара | 2 | 60 | 2 258,0 | 50 543,38 | 02.01.2025 – 30.04.2025; 01.10.2025 – 31.12.2025 |
| 27. | Казан | Тобольск | 2 | 101,5 | 6 606,0 | 123 667,5 | 02.01.2025 – 31.12.2025 |
| 28. | Казан | Улан-Удэ | 2 | 58 | 10 953,0 | 201 935,5 | 01.01.2025 – 30.04.2025; 01.10.2025 – 31.12.2025 |
| 29. | Казан | Усинск | 2 | 78 | 7 089,0 | 274 748,0 | 02.01.2025 – 30.06.2025; 01.09.2025 – 31.12.2025 |
| 30. | Казан | Чиләбе | 3 | 48 | 4 674,0 | 126 431,65 | 01.01.2025 – 30.04.2025; 01.10.2025 – 31.12.2025 |
| 31. | Казан | Ярославль | 2 | 54 | 3 708,0 | 83 987,24 | 02.01.2025 – 30.04.2025; 01.10.2025 – 31.12.2025 |
| 32. | Казан | Нарьян-Мар | 3 | 108 | 7 572,0 | 137 374,0 | 01.01.2025 – 31.12.2025 |
| 33. | Казан | Ханты-Мансийск | 2 | 104 | 7 089,0 | 137 374,0 | 01.01.2025 – 31.12.2025 |
| 34. | Түбән Кама | Нижневартовск | 2 | 49 | 8 538,0 | 403 871,0 | 01.01.2025 – 30.04.2025; 28.09.2025 – 31.12.2025 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 35. | Түбән Кама | Яңа Уренгой | 2 | 104 | 9 504,0 | 403 871,0 | 01.01.2025 – 31.12.2025 |
| 36. | Түбән Кама | Тобольск | 2 | 102,5 | 6 123,0 | 114 530,0 | 02.01.2025 – 31.12.2025 |